**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№411**
**30.01.2019**

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, аларның кеременең һәм мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ санлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, 2019 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче кеременең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче кеременең максималь күләме – 12 502 сум 86 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 831 060 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 1 662 120 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 2 493 180 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 324 240 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 4 155 300 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 4 986 360 сум;

- җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 817 420 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 6 648 480 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин